Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2022 ел № 53

Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 50 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә, шулай ук хокукый мониторинг тәртибендә

Миңлебай авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 50 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 54 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 9 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 49 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары» (алга таба- Тәртип) кушымтасының I бүлегенең 3 пунктын (алга таба - Тәртип) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Башлыкка, башлык урынбасарына, еллык түләүле отпуск биргәндә айлык акчалата түләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләкләүләр, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүләр, муниципаль хокукый актлар нигезендә премияләр түләнә.»;

«9) Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында башкарган өчен айлык компенсация түләве вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә;»;

д) түбәндәге эчтәлекле 10) пункт өстәргә:

«10) вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү:

Фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 1,5 процентыннан артмаган күләмдә;

Фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә;»;

е) 9) пунктчаны 11) пунктча дип санарга;

1.6. карарга 1 нче кушымтада түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (11 хезмәт өчен түләү төркеме) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19 032 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 18 652 |

1.7. карарга 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (11 хезмәт өчен түләү төркеме) |
|---|---|
| Башлык | 19 039 |
| Башлык урынбасары | 13 681 |

2. Әлеге карарны Миңлебай авылы,Ш.Бикчурин урамы, 50 йорт, Миңлебай станциясе, Шоссейная урамы, 20А йорт, торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1.2 пункты, 1.5 пунктының б) пунктчасы, 1.6, 1.7 пунктлары 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Миңлебай
авыл җирлеге башлыгы — И.М. Рәхимов